| АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.07.2020 п.г.т. Алексеевское № 334

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 01 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск район Советының 2019 елның 18 октябрендәге 269 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

- 10 маддәнең 2 пунктын, 50 маддәнең 1 абзацын, 53 маддәнең 3 пунктын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр (сроклар өлешендә) туктатып торырга;
- 27 маддәнең 2 пунктында «һәм башкарылалар» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 32 маддәнең 4 пунктында «һәм башкарыла» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 32 маддәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган муниципаль гарантия бары тик хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре генә тәэмин ителә

ала, аның акцияләренең 100 проценты (өлешләре) Районга, муниципаль унитар предприятиегә карый, аның мөлкәте Район милкендә»;

- 32 маддәнең 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия муниципаль гарантиядә күрсәтелгән төп йөкләмәләр шартлары муниципаль гарантиядә күрсәтелгән гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка үзгәртелмәгән очракта гына һәм (яисә) кредит (заем, шул исәптән облигация) белән тәэмин ителгән муниципаль гарантия акчаларыннан максатчан файдаланмаган очракта, кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитны максатчан куллануны тикшереп тору башкарыла»;

- 32 маддәнең 16 пунктының 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук ТР, Алексеевск районы, Алексеевск штб., Совет мәйданы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Алексеевск муниципаль районы Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**